Диндә көчләү юк, ләкин өндәү һәм өйрәту бар”
(Коръән Кәрим. 2-256)

# Ислам Нуры

№ 17 (645) 8 сентябрь, 2017 ел (1438, Зөлхиҗҗә) Дини-иҗтимагый газета 1995 елдан чыга

12+

## Күркәм бәйрәм



Көзнең тәүге аена иң күркәм бәйрәмнәребезнең берсе — Корбан гаете белән килеп кердек. Бу чара Чаллы мәчетләрендә бәйрәм вәгазьләреннән башланып, бик матур төстә узды. Шәһәр имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин гает намазын “Нур-Ихлас” мәчетендә укытты. Бәйрәм вәгазен тыңлаучылар арасында беренче рәттә шәһәр мэры Наил Гамбәр улы Мәһдиев, шәһәр эчке эшләр бүлеге башлыгы Надир Дамир улы Закиров та бар иде. Алар, шулай ук шәһәрнең Җәмигъ мәчете Попечительләр шурасы әгъзалары, мөхтәсибәттә Корбан гаете хөрмәтенә үткәрелгән аш мәҗлесендә катнаштылар. Биредә шәһәр мөселманнары өчен актуаль мәсьәләләр, шул исәптән яшь буынга рухи-әхлакый тәрбия бирү, Җәмигъ мәчете төзелеше барышы буенча фикер алышынды.

Гает намазыннан соң халык гает коймагыннан авыз итте. “Җәмигъ”, “Сөембикә”, “Чишмә”, “Ихлас” мәчетләрендә пылау белән дә сыйландылар. “Кәүсәр” мәчетендә икендедән соң мәчет картлары өчен корбан ашы оештырылды. Иң зур бәйрәмнәрнең берсе “Әбүзәр” мәчетендә үткәрелде. Биредә мең ярым кешегә пылау пешерелде, балалар өчен төрле аттракционнар эшләде.

Гает намазына кадәр үк Үзәкләштерелгән корбан чалу мәйданчыгына (Чаллыда менә 7 ел корбан чалу бер генә урында башкарыла) сатуга 1764 сарык кертелде. Биредә мал чалу һәм тунау хезмәте дә күрсәтелә.

Мохтаҗлар, церебраль авырулы балалар өчен корбан ите җыю оештырылган иде. Корбан чалучылар су, элеп тунау урыннары белән тәэмин ителгән, ветеринария контроле, ГИБДД, полиция посты эшли, мал калдыклары җыеп барыла, намаз бүлмәсе җиһазланган.

Үзәкләштерелгән корбан чалу мәйданчыгында корбан чалу барышы белән шәһәр мэры Наил Гамбәр улы да танышты. Ул мәйданчыкны камилләштерү, аның бер өлешен түбә астына алу, заманча биналар төзү кирәклеген искәртте, бу эшләрдә шәһәр җитәкчелеге ягыннан булышлык булачагына ышандырды.



**Рәсемнәрдә:** “Нур-Ихлас” мәчетендә бәйрәм вәгазен тыңлау. Алдагы рәттә — шәһәр мэры Наил Гамбәр улы һәм УВД башлыгы Надир Дамир улы; Гает намазы; корбан чалу мәйданчыгыннан күренеш.



## Аксакаллар җыелышты…

3 сентябрьдә “Туфан” мәчетендә Чаллы шәһәре Аксакаллар шурасының чираттагы утырышы узды. Рәсми чараның Корбан гаете көннәренә туры килүе җыелышны Аксакаллар шурасы рәисе Равил хәзрәт Нуруллин һәм имам-мөхтәсиб Әлфәс хәзрәт Гайфуллинның тәбрик сүзләре, Коръән аятьләре уку, ихлас дога кылу белән башлап җибәрергә мөмкинлек бирде. Утырышта өч көн тәртибе тәкъдим ителеп, иң башта Аксакаллар шурасы әгъзаларына таныклык тапшырылды. Икенче көн тәртибе буенча исә Чаллының мәктәп һәм балалар бакчаларында хәләл туклануны булдыру мәсьәләләре күтәрелде. Әлеге сорау нигезендә апрель аенда шәһәр хакиме Н.Г.Мәһдиевка хат юлланып, “ата-аналар ризалыгы булганда, моны эшләргә мөмкин” дигән уңай эчтәлектәге җавап та алынган инде. Шуңа бәйле рәвештә, аксакалларга мәктәп, балалар бакчаларына барып, җитәкчеләр һәм ата-аналар белән күзгә-күз очрашып сөйләшергә дигән бурыч та йөкләнде. Хәләл ризык дигәндә, нәрсә күздә тотыла, сәламәтлек өчен файдасы нидән гыйбарәт — болар хакында дәлилле итеп аңлату кирәклеге дә әйтелде.



“Хәләл туклануның сәламәтлеккә файдалы икәнен табиблар да раслый. Хәләл ризык белән бергә балаларыбызның күңеленә иман, әхлак орлыклары да салына; ата-аналарга, беркемне мәҗбүриләмичә, менә шушы хакыйкатьне төшендерергә, хәләл белән хәрәмнең аермасын аңлатырга иде”, - диде Әлфәс хәзрәт үзенең кыска, әмма тирән мәгънәле чыгышында.

Өченче көн тәртибе төрле мәсьәләләрне карауны күздә тота иде. Аксакаллар үзләрен кызыксындырган сорауларны биреп, аларга төпле җавап алдылар. Утырышта шәһәр башкарма комитетының җәмагатьчелек белән элемтә бүлеге җитәкчесе Рөстәм Галиуллин да катнашты.

Өйлә намазыннан соң Әлфәс хәзрәт кыскача вәгазь сөйләде. Равил хәзрәтнең күркәм бәйрәме — 60 яшьлек юбилее уңаеннан, аңа матур теләкләр, котлаулар ирештерелде. Чара соңында мәчеттә корбан ашы да уздырылды.



## ХЕЗМӘТЕНӘ КҮРӘ ХӨРМӘТЕ

Рухи-әхлакый традицияләрне үстерүгә, тынычлыкны һәм конфессияара татулыкны ныгытуга зур өлеш кертүе өчен Чаллы шәһәре имам-мөхтәсибе Әлфәс хәзрәт Гайфуллин Татарстан Республикасы Президентының Рәхмәт хаты белән бүләкләнде. Хатны 25 августта “Нур-Ихлас” мәчетендә, җомга намазында Чаллы шәһәренең Үзәк районы Башкарма комитеты җитәкчесе Галимов Искәндәр Галим улы тапшырды. Ул Әлфәс хәзрәткә киләчәктә дә актив эшчәнлек, саулык-сәламәтлек теләде.

# ГЫЙЛЕМНЕҢ ДӘВАМЛЫ БУЛУЫ ХӘЕРЛЕ

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Гыйлемне өйрәтүче йә булмаса өйрәнүче, йә булмаса яратучы бул, әмма гыйлемне яратмаучы, галимне хөрмәт итмәүче булма!» - диде. Без һәрвакыт гыйлем алырга омтылырга, үзебезгә савап җыярга тиешбез.

**Җәлил хәзрәт Фазлыев,**
**Татарстанның баш казые:**

1 нче сентябрь – гыйлем көне. Белем көне дип, мәктәпләрдә укулар башлана. Шуңа күрә дә бу вәгазем гыйлем турында. Безгә, мөселманнарга, «Ләәә иләәһә илләллааһ Мүхәммәдүр Расүүлүллааһ», дип әйткәннән соң, ягъни иман китергәннән соң, биш төрле төп фарыз гамәл йөкләтелә. Намаз, ураза, зәкят, хаҗ, иманны белү. Бу фарызларны төгәлрәк итеп, тәфсилләбрәк карасак, алар 40 ка җыела. Мәсәлән, намазның үзендә генә дә: эчендә – 8, тышында – 8, җәмгысе 16 фарызы бар. Фарызларның берсе — гыйлем эстәү. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) әйтте: «Адәм баласына бишектән алып ләхеткә хәтле гыйлем алу фарыз», – диде. Шуңа күрә без, ничә яшьтә булуыбызга карамастан, һәрвакыт гыйлем алырга омтылырга тиешбез.

Шундый бер риваять бар. Бер кеше 70 яшендә Пәйгамбәребез янына килеп: «Инде нинди изге гамәл кылыйм?» – дигәч, Мөхәммәд (с.г.в.) аңа: «Гыйлем эстә!» – дигән. Шушы кеше Пәйгамбәребезнең кушканын тотып, гыйлем алып, аннан соң балалар укыта башлап, 95 яшенә җитеп вафат була. 20 елдан артык балалар укыта. Бу хәл үзе үк инде гыйлем эстәргә беркайчан да соң түгел икәнне күрсәтеп тора. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Әгәр бер кеше, гыйлем алу нияте белән, өеннән чыгып китсә, ул әйләнеп кайтканчы, Аллаһның бөтен фәрештәләре, бөтен мәхлукате, хәтта судагы балыклар да бу кеше өчен хәер-дога кылып торырлар», – диде (Мөслим, Тирмизи). Әгәр без гыйлем алу, вәгазь тыңлау, нәрсә дә булса белү нияте белән җомгаларга йөрсәк, Коръән мәҗлесләрендә булсак, йә булмаса берәр галим янына барсак – бу инде безнең гыйлем эстәвебез булып тора.

Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Гыйлемне өйрәтүче йә булмаса өйрәнүче, йә булмаса яратучы бул, әмма гыйлемне яратмаучы, галимне хөрмәт итмәүче булма!» – диде. Без һәрвакыт гыйлем алырга омтылырга, үзебезгә савап җыярга тиешбез.

Гыйлем ике төрле: дөньяви гыйлем һәм ахирәт гыйлеме. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) безгә шушы ике гыйлемне дә тигез күрергә кушты.

Балаларның әти-әнисе өстендә булган хакларының да берсе шул: алар баласына дөньяви һәм дини гыйлемне өйрәтергә тиеш. Бүген дөньяви гыйлемне мәктәпләрдә бирәләр икән, баламны мәктәптә укыталар инде, дип, аны өйдән киендереп чыгарып җибәрү белән генә эш бетми. Бала нәрсә укый, ничек укый, дип, аның укуы белән, үз-үзен тотышы белән кызыксынып торырга кирәк. Балага дин гыйлеме дә бирелсен. Дини гыйлем бирү – шулай ук әти-әни өстендәге бурыч. Әгәр ата-ана баласына дини гыйлемне бирмәсә, аның бер бурычы үтәлмәгән була. Ул үзе белмәсә, башка кешегә барып, баламны намаз укырга өйрәт, дип сорасын. Шулай иткәндә әти-әнисенең өстеннән бурычы төшә. Дини гыйлемнең нигезе – Аллаһны тану. Чөнки «Аятел көрси»дә шундый сүзләр бар («Әл-Бәкара» сүрәсе, 255 нче аять): Аллаһ Раббыбыз әйтә: “Гыйлемне сез Мин теләгән хәтле генә белерсез”, – ди. Гыйлемнең чыганагы, нигезе булып Аллаһ тора. Бәндәләр Аллаһ теләгән хәтле генә гыйлем ала алалар. Ул теләгән хәтле генә белә алалар. Галимнәр нинди зур ачышлар ясасалар да, бу – Аллаһның аларга биргән бер бүләге, һидәяте. Мәктәпләрдә гыйлемлеккә өйрәтәләр, әмма шуны тудырган Аллаһны танырга өйрәтмиләр. Бу хәл балаларны төрле бозыклыкларга, дөрес булмаган юлларга кертеп җибәрә. Мисал итеп бер урындыкны гына алыйк. Без аны күреп торабыз: аягы бар, утыргычы бар, агачтан ясалганын да беләбез, әмма аны кем ясаган – анысын без белә алмыйбыз. Бүгенге фәнне өйрәнүебез дә шуның шикелле. Аллаһ Раббыбыз җирләрне, күкләрне бар итте, анда үзенең кануннарын, тарту көчләрен, җирнең кояш тирәли һәм үз күчәрендә әйләнүләрен, матдәләр составын, молекула төзелешләрен – бөтенесен өйрәнәбез, әмма шуларны юктан бар итүче Аллаһы Тәгаләне читтә калдырабыз. Мәктәпләрдәге укытулар гел берьяклы булып кала, шуңа кирәкле нәтиҗәгә ирешә дә алмыйбыз.

Һавада оча торган кошлар да ике канатлы. Алар бер генә канатлы булсалар, оча алмыйлар, һәлак булалар. Әгәр без балаларга бер гыйлемне генә бирсәк, алар да һәлак була. Дөньяви гыйлем белән генә кеше ерак китә алмый. Ул ахирәтендә җәһәннәмгә элә(г)ә, ә дөньялыкта күбесе әхлаксыз булып, бернәрсәдән дә курыкмый, әти-әниләрен хөрмәт итми, өлкәннәрне өлкән итми, теләсә нәрсә эшли торган бозык шәхес булып үсә. Бу Аллаһны танымаудан, Аңардан курыкмаудан килә. Фәкать дини гыйлемне генә бирсәк тә балаларыбыз надан кешеләр булып калыр. Милләт яшәсен өчен, аның көчле, бай, мәгърифәтле булуы шарт. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Дөнья эшендә сез үзегез күп беләсез», – диде. Димәк, дөнья эшләре буенча булган гыйлемнәргә, тәҗрибәләребезгә таяну сорала. Дөнья гыйлемнәрен тормыштан алырга һәм үзләштерергә тиешбез. Дини гыйлемле кеше дөнья байлыгын да теләсә нинди юл белән тапмас, теләсә нинди җиргә тотмас, ризыкның да теләсә ниндиен ашамас. Дини гыйлемле кеше акыллы яши, хайван шикелле тормыш алып бармый. Аллаһы Тәгалә кушканча гомер кичерә. Коръәни Кәрим белән хәдистә адәм баласы ничек итеп әхлагын төзәтергә, ничек итеп яшәргә, ничек итеп Аллаһны олугларга тиеш – барысы да күрсәтелгән, бөтенесе бәйнә-бәйнә аңлатылган. Әмма дөнья көтәр өчен бу гына җитми. Шуңа дөньяви гыйлемнәрне өйрәнү дини гыйлемнәр белән бергә алып барылырга тиеш. Шулай иткәндә ул һавада очкан ике канатлы кош шикелле күркәм кеше булыр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) әйтте: «Гыйлемнең әз булса да дәвамлы булганы хәерлерәк», – диде. Берәү намаз укырга өйрәнә, биш вакыт намазын укый башлый. Һәм аны мөмкин булган хәтле мәчеткә йөреп укырга тырыша. Берәү намаз укырга да өйрәнә, Коръән китабын да ятлап бетерә, әмма намазында дәвамчылык күрсәтми, мәчеткә йөрми. Коръәнне болай ятлау бер тиенгә дә тормый, чөнки ул Аллаһның Коръәндә кушканын үтәми. Хәтта фарыз гамәлнең фарыз икәнен аңларга җитми аның гыйлеме. Гыйлемлек булмый бу.

Җомганы без ике гаеттән олы булган бәйрәм дип әйтәбез. Ни өчен шулай ул? Чөнки җомганың вәгазе ике рәкагать намазны алыштыра. Өйлә намазы – дүрт рәкагать фарыз. Җомгада – ике рәкагать кенә фарыз. Чөнки ике рәкагать фарызны вәгазь алыштыра. Бу – мәҗбүри. Вәгазь сөйләнмәсә, җомга булып китми. Хәтта гаеттә дә вәгазь сөйләү мәҗбүри түгел, җомгада – мәҗбүри. Шуңа да җомга намазына килгән кеше вәгазь тыңлап, ниндидер гыйлем алып кайта. Шуның белән ул кыйммәтле. Ә гаеттә вәгазь ирекле. Җомгада – фарыз. Коръән ашларында да әзме-күпме вәгазь сөйләнергә тиеш. Күпмедер Коръән аяте укып, намаз калдырып, гайбәт сөйләшеп утырып кына таралышсак, бу табын Коръән табынына саналмый, ул үз вазыйфасын үтәмәгән була. Кеше Коръән мәҗлесенә ашап-эчәр, сәдака алышыр өчен генә килергә тиеш түгел. Вәгазь сөйләнергә, дини мәсьәләләр тикшерелергә тиеш.

Кайчак мондый мәҗлес хакына намазларыбыз да калып тора, ә без нәрсәдер сөйләшеп кенә утырабыз. Вәгазь юк, гыйлем алу юк, табынның нәтиҗәсе юк. Без балаларыбызны да, өлкәннәребезне дә дини гыйлемгә, Ислам дине кануннарына өйрәтергә тиешбез. Чөнки Аллаһы Тәгалә Коръәндә әйтте («Фуссыиләт» сүрәсе, 33 нче аять): “Аллаһка иман китерергә, изгелеккә кешеләрне чакыручы һәм игелекле гамәлләр кылучы мөселманның сүзеннән дә күркәмрәк, файдалырак сүз булырмы, һәм ул әйтәдер: мин мөселман, бу эшләрне эшләргә мин бурычлымын, дип”.

Һәм аны гамәле белән дә ныгытса, ул чын кеше, мөселман була.

Гыйлемнең күләме аның гамәле белән исәпләнә. Кемнеңдер күпмедер догаларны яттан белүе – бер хәл, аларны гамәлдә файдаланырга кирәк. Иң беренче – намаз, аннан зәкят, аннан ураза. Кеше аны ничек үти? Җәмәгать белән мәчеттә намаз укыймы? Өендә укыймы, әллә бөтенләй үтәмиме. Динне кайгырту, Аллаһны танудан соң, шушы эшләрдән башлана: ничек итеп тәһарәт аласы, ничек намаз укыйсы, нинди гамәлне күбрәк кыласы?

Кайбер картлар әйтә: «Безнең тел әйләнми инде, ул «Кулһүаллаһ»ны укып булмас инде», – диләр. Барысы да күңел бирүдән тора. Аллаһтан курку, Аңа инану җитми. Ахирәтне икенче, арткы якка куярга тиеш түгелбез. Алай итсәк, без һәлакәткә барабыз. Гыйлемебез шул хакыйкатьне аңларлык дәрәҗәдә булырга тиеш.

Аллаһы Тәгалә «Әл-Фәләк» («Таң») сүрәсенең 3 нче аятендә болай дип әйтә: “Караңгылыктан килгән зарардан Аллаһ Үзеңә сыенамын”, – ди. «Караңгылык» бу урында – наданлык дигән сүз. Кайчак белмәвебез аркасында, ярамаган эш эшлибез, савап булыр дип өмет итәбез, ә ул бер тиенгә дә тормый торган гамәл була. Икенчесен эшлибез, ул фарыз була, төп эш була. Нәрсә фарыз, нәрсә сөннәт яки вәҗиб, мөстәхәб икәнен без белергә тиеш. Намазда да, бүтән гамәлдә дә хәрамны, мәкруһны, мөбәхны, мөстәкраһны белеп эш итик. Исламда булган 8 төрле нәрсәне белмәү аркасында кайвакыт мәчетләребездә дә, кеше арасында да низаг чыга.

Хак Тәгалә мәчеткә йөрүләребезне, вәгазь тыңлауларыбызны кабул итеп, үзара сөйләшеп, үзара килешеп, белгәннәребезне уртаклашып, дус булып, тату булып яшәүләребезне насыйп итсә иде.

ӘДӘБИ СҮЗ

*Габдулла Тукай*

## Таян Аллага

*Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!*
*Йа Ходай, күрсәт, диген, ушбу җиһанда якты юл;*
*Ул – рәхимле; әткәң-әнкәңнән дә күп шәфкатьле ул!*
*Саф әле күңлең синең, һичбер бозык уй кермәгән,*
*Пакь телең дә һич ярамсыз сүзләр әйтеп күрмәгән.*
*Пакь җаның һәм пакь тәнең – барлык вөҗүдең пакь синең:*
*Син фәрештә валчыгысың, йөзләрең ап-ак синең!*
*Кыйл дога, ихлас белән тезлән дә кыйбла каршына;*
*Бел аны: керсез күңелдән тугъры юл бар гаршенә!*
*Әй бәһале, әй кадерле, әй гөнаһсыз яшь бала!*
*Рәхмәте бик киң аның, һәрдәм таян син Аллага!*

***Гаршенә – югарыга, күккә.***

## Ана догасы

*Менә кич. Зур авыл өстендә чыкты нурлы ай калкып,*
*Көмешләнгән бөтен өйләр, вә сахралар тора балкып.*
*Авыл тын; иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп арган*
*Халык йоклый – каты, тәмле вә рәхәт уйкуга талган.*
*Урамда өрми этләр дә, авыл үлгән, тавыш-тын юк;*
*Авыл кырыенда бер өйдә фәкать сүнми тора бер ут.*
*Әнә шул өй эчендә ястүеннән соңра бер карчык*
*Намазлыкка утырган, бар җиһаннан күңлене арчып;*
*Күтәргән кул догага, яд итә ул шунда үз угълын:*
*Ходаем, ди, бәхетле булсайде сөйгән, газиз угълым!*
*Тамадыр мискинәмнең тамчы-тамчы күзләреннән яшь;*
*Карагыз: шул догамы инде тәңре каршына бармас?*

***Уйку – йокы***
***Яд итү – исенә төшерү***

# Кешеләргә шатлык бүләк итик

***(Мәчет картлары сөйләгәннәрдән)***

Безнең мәчет картларыниләр генә белми дә, ниләр генә сөйләми. Аларны игътибар белән тыңлап, сөйләгәннәрен калеб аша үткәрсәң, "хикмәтләрнең хикмәте бит бу!" дип сокланмыйча калмассың.

Күңелемне айкалдырып алган, башкаларга карата тагын да дикъкать-ихтирамлырак булырга өйрәткән әлеге хәл бик күптән — бабайларыбыз үзләре чая малай-шалай чакларында булган. Халык җирне сука белән сукалап, игенне урак белән урып, басу-кырларда эшләп йөргән элекке заман бу. Ул вакытта мәчет-мәдрәсәләрдә уку күп кеше өчен төп гыйлем алу урыны булып саналганын да әйтеп узарга кирәктер...

...Шулай бервакыт мәдрәсәдә белем алучы шәкерт һәм аның остазы өйләренә кайтырга дип юлга чыгалар. Авыл янәшәсендәге басуга килеп җиткәч, ызаннарның берсендә шәкерт бик тә иске күренгән башмаклар күреп ала. Басуның икенче кырыенда, шактый еракта бертөркем игенчеләр эшләп эшләп йөри икән. Шушы аяк киемен аларның берсе салып калдырганын абайлаган шәкерт, шаян холыклы булгангадыр, күзләрен ялтыратып, остазына болай дигән:

— Әйдәгез, башмакларны яшереп куйыйк, ә үзебез агачлар артына басып, иясенең моны ничек кабул итүен күзәтербез! Вәт кәмит-тамаша булачак!

Ләкин мөгаллим болай итеп уен-көлке ясарга, ягъни кемнеңдер күңелен төшереп шаярырга ярамаганын әйтеп, башка фикер әйтә.

— Алар бер фәкыйрь кешенеке булырга тиеш, шуңа күрә без болай эшлик: башмаклар эченә акча тыгып, үзебез агачлар артына басыйк та, ни буласын күзәтик.

Остаз сүзе — катгый канун дигәндәй, шулай эшлиләр дә: һәр башмакка кәгазь акчалар куеп, куе агачлар артына яшеренәләр болар. Озак вакыт үтми — басуның икенче ягыннан бер ир кеше ава-түнә көч-хәл белән аларга таба атлап якыная башлый. Көн бик матур, аяз һәм кояшлы булса да, абзыйның йөзе кап-караңгы болыт булып күренә. "Кызу кояш астында озак эшләп, бик арыган бу, ахрысы", — дип шәкертнең пышылдап кына әйтүенә каршы мөгаллим: "Юк, энем, болай алпан-тилпән йөрүеннән аның берничә көн юньле ризык капмаганын аңлап була, абзыйның тамагы ач, күрәмсең..." — дип шулай ук пышылдап җавап кайтара.

Башмаклары янына килеп утыргач, игенче авыр итеп сулап куя да, йөзен учлары белән каплап, тын кала. Ул нәрсә турында уйлап утыргандыр, ләкин шушы күренештән шәкертнең шаян уйлары юк була, алай гына да түгел — күңелен ниндидер куркыныч, шомлы хис биләп ала. Битен, башын уалап алганнан соң, абзый уң башмагын киям дигәндә кинәт туктап кала. Аннары кулын башмагы эченә тыгып, шундагы акчаны чыгара да, бермәл шуңа бик аптырап, сәерсенеп карап утыра. Икенче башмагы эчен капшап, анда да акча булуын күргәч, игенче... сәҗдәгә китә һәм сәҗдәдән торгач, тезләнгән хәлдә кулларын күккә таба күтәрә дә, рәхмәтләрен укый башлый:

— Минем хатыным каты авырганын, балаларым ач булганын, гаиләм бер кисәк икмәккә тилмергәнен белүче и бөек Раббым! Безне үлемнән коткарганың өчен шөкер итәм! Дөрестән дә, Син догаларны кабул итүче, Ярлыкаучы, Коткаручы, Мәрхәмәтле бөек илаһи Зат! Рәхмәт Сиңа, йә Аллаһ!

Абзый тагын сәҗдәгә китә, шул хәлдә рәхмәт укуларын әле тагын дәвам итә. Остаз шәкертне җиңеннән тартып, "китәбез" дип ымлап ишарәләгәч, егет шушы күренеш тәэсирендә башта урыныннан кузгала алмыйча тора. Соңыннан агачлыкның икенче ягыннан чыгып, алар юлларын дәвам итәләр. Шәкерт, күңеле тулып, тавыш-тынсыз гына елый.

— Шушы күз яшьләрең көенечтәнме, сөенечтәнме? — дип сорый укучысыннан остазы.

— Сөенечтән, хәлфәм, сөенечтән! — ди егет елмаерга талпынып. — Бу гомеремдә дә онытылмаслык бик гыйбрәтле бер хәл булды минем өчен. Рәхмәт сезгә, остазым!

— Әйе, энем, бу абзыйның аяк киемен яшереп куюдан син күпмедер дәрәҗәдә күңел ачып, үзеңә уен-көлке ясар идең бәлки. Ләкин шуннан тойган сөенечең хәзерге шатлыгың белән тигезләшә аламы соң? Хак иман ияләре башкаларга борчу-хәвеф түгел, ә бары тик шатлык бүләк итәргә тиеш. Шулай гамәл кылган кешене Аллаһы Тәгалә үзен шатландырыр, бер-беребезне сөендерү нәтиҗәсендә бу дөньяда нур-изгелек артыр, игелек явызлыкны җиңәр. Шуңа күрә дә кешеләргә шатлык бүләк итик, кардәш, фәкать шатлык кына бүләк итик!

**Ришат хәзрәт Курамшин,**
**Кукмара шәһәре.**

# Колак салсаң, үкенмәссең

* Әгәр сине яхшы эшләрең шатландырса һәм бозык эшләрең кайгыга салса, димәк, син мөэмин икәнсең.

* Хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы — ир хакы, ирләр һәм хатыннар өстендә булган хакларның иң зурысы — ана хакы.

* Биш нәрсә килгәнче, башка бишнең кадерен бел: үлемең килгәнче — терек булуыңның, хасталык килгәнче — сәламәтлегеңнең, мәшгуль булганчы — буш вакытыңның, картлык килгәнче — яшьлегеңнең, фәкыйрьлек килгәнче — байлыгыңның.

* Галим, яки гыйлем өйрәнүче, яки тыңлаучы, яки гыйлемне сөюче бул! Ләкин бишенчесе булма, һәлак булырсың!

* Кәсепнең иң яхшысы — хыянәтсез булган сәүдә һәм кешенең үз кул көче белән мал табу.

* Кыямәт көнендә гөнаһы иң күп булган кеше — дөньяда вакытта әһәмиятсез сүзне күп сөйләгән кеше.

* Ара бозык тору — кешеләрне һәлак итүче.

* Әманәтле булу — ризыкны, хыянәтле булу фәкыйрьлекне тарта.

* Синдә Аллаһы Тәгалә сөя торган ике сыйфат бар: йомшаклык һәм кабаланмау.

* Эшләрнең хәерлесе — уртачасы.

# Локман Хәким хикмәтләре

Локман Хәким хикмәткә ия булгач, үзенең хатынын һәм балаларын бер Аллаһны гына танырга, Аңа гына гыйбадәт кылырга, Аңа ширек кылмаска чакыра. Зур гөнаһларның да иң зурысы булган ширек катудан улын тыйганнан соң, Локман Хәким кечкенә гөнаһлардан да сакланырга куша. Пәйгамбәребез (с.г.в.): "Зур гөнаһлар кечкенә гөнаһлар эченә, зур саваплар кечкенә савап эченә яшеренгән", — диде. Үкенеп тәүбә кылган зур гөнаһ — гөнаһ булудан туктый. Без зур гөнаһ эшләсәк борчылабыз, шул ук вакытта кечкенә гөнаһка артык әһәмият бирмибез, шуның нәтиҗәсендә аңа ияләнеп тә китәбез.

Зур гөнаһы өчен кайгырып йөрүче, кечкенә гөнаһны уйламаучы ике кешегә Локман Хәким эш куша. Берсенә биш килограммлы бер таш алып килергә, икенчесенә биш килограммлы вак таш җыярга куша. Алар бу эшне эшләгәч: "Инде урыннарына илтеп куегыз", — ди. Вак таш җыючы: "Мин урыннарын хәтерләмим, бу эш минем көчтән килми", — ди. Локман Хәким: "Кечкенә гөнаһлар шул ягы белән куркыныч — аларны хәтерләп һәм тәүбә кылып бетерергә мөмкин түгел, алар ахирәткә дә гөнаһ булып баралар", — ди.

Локман Хәкимнең хуҗасы да вак-төяк гөнаһларга салкын карый, исе китми... Яз көне, хуҗасы бодай чәчәргә кушкан басуга Локман Хәким арпа чәчә. Игеннәр тишелеп чыгып, үсә башлагач, хуҗа кеше басуга килә һәм: "Нишләп арпа чәчтең?" — дип сорый. "Борчылма, — ди Локман Хәким, — үскәч алар бодайга әйләнәчәк". "Җүләр, бу эш мөмкин түгел", — дигәч, "Дөнья — ахирәтнең иген кыры, ни чәчсәң — шуны урырсың. Син кечкенә гөнаһлар дип, гөнаһ чәчеп йөреп, нәрсә урмакчы буласың?" — дип җавап кайтара.

# Намаз вакытлары

| Милади Октябрь | Көн исеме | Мөхәррәм, сәфәр | Иртәнге намаз: Таң беленә | | | Иртәнге намаз: Мәчетләрдә укыла | | | Кояш чыга | | | Зәвәл | | | Өйлә | | | Икенде | | | Ахшам | | | Ясту | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан | Уфа | Чаллы | Казан |
| 1 | Як | 11 | 05.15 | 03.27 | 03.40 | 05.46 | 04.01 | 04.15 | 07.18 | 05.31 | 05.45 | 13.05 | 11.20 | 11.33 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.51 | 15.06 | 15.19 | 18.48 | 17.07 | 17.20 | 20.29 | 18.48 | 19.02 |
| 2 | Дш | 12 | 05.17 | 03.29 | 03.42 | 05.48 | 04.03 | 04.17 | 07.20 | 05.33 | 05.47 | 13.04 | 11.19 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.49 | 15.04 | 15.17 | 18.50 | 17.04 | 17.17 | 20.26 | 18.46 | 18.59 |
| 3 | Сш | 13 | 05.19 | 03.31 | 03.44 | 05.50 | 04.05 | 04.19 | 07.22 | 05.35 | 05.49 | 13.04 | 11.19 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.47 | 15.02 | 15.15 | 18.48 | 17.02 | 17.15 | 20.25 | 18.43 | 18.56 |
| 4 | Чш | 14 | 05.21 | 03.33 | 03.46 | 05.52 | 04.07 | 04.21 | 07.24 | 05.37 | 05.51 | 13.04 | 11.19 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.45 | 15.00 | 15.13 | 18.45 | 16.59 | 17.12 | 20.23 | 18.40 | 18.53 |
| 5 | Пж | 15 | 05.23 | 03.36 | 03.49 | 05.54 | 04.09 | 04.23 | 07.26 | 05.39 | 05.53 | 13.04 | 11.18 | 11.32 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.42 | 14.57 | 15.10 | 18.43 | 16.56 | 17.10 | 20.21 | 18.38 | 18.51 |
| 6 | Жм | 16 | 05.25 | 03.38 | 03.51 | 05.56 | 04.11 | 04.24 | 07.28 | 05.41 | 05.54 | 13.04 | 11.18 | 11.31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.40 | 14.55 | 15.08 | 18.40 | 16.54 | 17.07 | 20.19 | 18.36 | 18.48 |
| 7 | Шм | 17 | 05.27 | 03.40 | 03.53 | 05.58 | 04.13 | 04.26 | 07.30 | 05.43 | 05.56 | 13.03 | 11.18 | 11.31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.38 | 14.53 | 15.06 | 18.38 | 16.51 | 17.04 | 20.16 | 18.32 | 18.45 |
| 8 | Як | 18 | 05.29 | 03.42 | 03.55 | 06.00 | 04.15 | 04.28 | 07.32 | 05.45 | 05.58 | 13.03 | 11.18 | 11.31 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.36 | 14.50 | 15.03 | 18.35 | 16.49 | 17.02 | 20.14 | 18.30 | 18.43 |
| 9 | Дш | 19 | 05.31 | 03.44 | 03.57 | 06.02 | 04.17 | 04.30 | 07.33 | 05.47 | 06.00 | 13.03 | 11.17 | 11.30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.34 | 14.48 | 15.01 | 18.33 | 16.46 | 16.59 | 20.11 | 18.27 | 18.40 |
| 10 | Сш | 20 | 05.33 | 03.46 | 03.59 | 06.03 | 04.19 | 04.32 | 07.35 | 05.49 | 06.02 | 13.02 | 11.17 | 11.30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.31 | 14.46 | 14.59 | 18.30 | 16.44 | 16.57 | 20.09 | 18.25 | 18.38 |
| 11 | Чш | 21 | 05.35 | 03.48 | 04.01 | 06.05 | 04.21 | 04.35 | 07.37 | 05.51 | 06.05 | 13.02 | 11.17 | 11.30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.29 | 14.44 | 14.57 | 18.28 | 16.41 | 16.54 | 20.06 | 18.22 | 18.35 |
| 12 | Пж | 22 | 05.37 | 03.50 | 04.03 | 06.07 | 04.23 | 04.37 | 07.39 | 05.53 | 06.07 | 13.02 | 11.16 | 11.30 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.27 | 14.41 | 14.54 | 18.25 | 16.39 | 16.52 | 20.04 | 18.20 | 18.33 |
| 13 | Жм | 23 | 05.39 | 03.52 | 04.05 | 06.09 | 04.25 | 04.39 | 07.41 | 05.55 | 06.09 | 13.02 | 11.16 | 11.29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.25 | 14.39 | 14.52 | 18.23 | 16.36 | 16.49 | 20.02 | 18.17 | 18.30 |
| 14 | Шм | 24 | 05.41 | 03.54 | 04.07 | 06.11 | 04.27 | 04.41 | 07.43 | 05.57 | 06.11 | 13.01 | 11.16 | 11.29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.23 | 14.37 | 14.50 | 18.21 | 16.34 | 16.47 | 19.59 | 18.15 | 18.28 |
| 15 | Як | 25 | 05.43 | 03.56 | 04.09 | 06.13 | 04.29 | 04.43 | 07.45 | 05.59 | 06.13 | 13.01 | 11.16 | 11.29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.21 | 14.35 | 14.48 | 18.18 | 16.31 | 16.44 | 19.55 | 18.12 | 18.25 |
| 16 | Дш | 26 | 05.45 | 03.58 | 04.11 | 06.15 | 04.31 | 04.45 | 07.47 | 06.01 | 06.15 | 13.01 | 11.16 | 11.29 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.18 | 14.32 | 14.45 | 18.16 | 16.29 | 16.42 | 19.52 | 18.10 | 18.23 |
| 17 | Сш | 27 | 05.47 | 04.00 | 04.13 | 06.17 | 04.33 | 04.47 | 07.49 | 06.03 | 06.17 | 13.01 | 11.15 | 11.28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.16 | 14.30 | 14.43 | 18.13 | 16.26 | 16.39 | 19.50 | 18.08 | 18.21 |
| 18 | Чш | 28 | 05.49 | 04.02 | 04.15 | 06.19 | 04.36 | 04.49 | 07.51 | 06.06 | 06.19 | 13.00 | 11.15 | 11.28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.14 | 14.28 | 14.41 | 18.11 | 16.24 | 16.37 | 19.48 | 18.05 | 18.18 |
| 19 | Пж | 29 | 05.51 | 04.04 | 04.17 | 06.21 | 04.38 | 04.51 | 07.53 | 06.08 | 06.21 | 13.00 | 11.15 | 11.28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.12 | 14.26 | 14.39 | 18.09 | 16.21 | 16.34 | 19.46 | 18.03 | 18.16 |
| 20 | Жм | 30 | 05.53 | 04.06 | 04.19 | 06.23 | 04.40 | 04.53 | 07.55 | 06.10 | 06.23 | 13.00 | 11.15 | 11.28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.10 | 14.24 | 14.37 | 18.06 | 16.19 | 16.32 | 19.43 | 18.01 | 18.14 |
| 21 | Шм | 1 | 05.54 | 04.08 | 04.21 | 06.25 | 04.42 | 04.55 | 07.57 | 06.12 | 06.25 | 13.00 | 11.15 | 11.28 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.08 | 14.21 | 14.34 | 18.04 | 16.17 | 16.30 | 19.41 | 17.58 | 18.11 |
| 22 | Як | 2 | 05.56 | 04.10 | 04.23 | 06.27 | 04.44 | 04.57 | 07.59 | 06.14 | 06.27 | 13.00 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.06 | 14.19 | 14.32 | 18.02 | 16.14 | 16.27 | 19.39 | 17.56 | 18.09 |
| 23 | Дш | 3 | 05.58 | 04.12 | 04.25 | 06.29 | 04.46 | 04.59 | 08.01 | 06.16 | 06.29 | 13.00 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.04 | 14.17 | 14.30 | 17.59 | 16.12 | 16.25 | 19.37 | 17.54 | 18.07 |
| 24 | Сш | 4 | 06.00 | 04.14 | 04.27 | 06.31 | 04.48 | 05.01 | 08.03 | 06.18 | 06.31 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.02 | 14.15 | 14.28 | 17.57 | 16.09 | 16.22 | 19.35 | 17.52 | 18.05 |
| 25 | Чш | 5 | 06.02 | 04.16 | 04.29 | 06.33 | 04.50 | 05.03 | 08.05 | 06.20 | 06.33 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 16.00 | 14.13 | 14.26 | 17.55 | 16.07 | 16.20 | 19.33 | 17.50 | 18.03 |
| 26 | Пж | 6 | 06.04 | 04.18 | 04.31 | 06.35 | 04.52 | 05.05 | 08.07 | 06.22 | 06.35 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.57 | 14.11 | 14.24 | 17.53 | 16.05 | 16.18 | 19.31 | 17.48 | 18.01 |
| 27 | Жм | 7 | 06.05 | 04.20 | 04.33 | 06.37 | 04.54 | 05.07 | 08.09 | 06.24 | 06.37 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.55 | 14.09 | 14.22 | 17.50 | 16.03 | 16.16 | 19.29 | 17.45 | 17.59 |
| 28 | Шм | 8 | 06.07 | 04.22 | 04.35 | 06.39 | 04.56 | 05.10 | 08.11 | 06.26 | 06.40 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.53 | 14.07 | 14.19 | 17.48 | 16.00 | 16.13 | 19.27 | 17.43 | 17.57 |
| 29 | Як | 9 | 06.09 | 04.23 | 04.37 | 06.41 | 04.58 | 05.12 | 08.13 | 06.28 | 06.42 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.52 | 14.04 | 14.17 | 17.46 | 15.58 | 16.11 | 19.25 | 17.41 | 17.55 |
| 30 | Дш | 10 | 06.11 | 04.25 | 04.38 | 06.43 | 05.00 | 05.14 | 08.15 | 06.30 | 06.44 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.50 | 14.02 | 14.15 | 17.44 | 15.56 | 6.09 | 19.23 | 17.39 | 17.53 |
| 31 | Сш | 11 | 06.13 | 04.27 | 04.40 | 06.45 | 05.03 | 05.16 | 08.17 | 06.33 | 06.46 | 12.59 | 11.14 | 11.27 | 13.30 | 12.00 | 12.00 | 15.48 | 14.00 | 14.13 | 17.42 | 5.54 | 16.07 | 19.21 | 17.38 | 17.51 |

## БАЛАЛАР БӘЙРӘМ ИТӘ

3 сентябрьдә Чаллының "Нур-Ихлас" мәчете янында балалар өчен бик матур бәйрәм узды. Мөхтәсибәт әлеге чараны Корбан гаете уңаеннан оештырган иде. Сабыйлар түләүсез аттракционнарда күңел ачтылар, поп-корн, "шикәрле мамык", пылау ашап хозурландылар, төрле спорт уеннарында ярыштылар. Коръән сүрәләре укыдылар. Җиңүче балалар буш кул белән китмәделәр: алар үзләренә бирелгән билетларны "Афәрин кибете" киштәсендәге бүләккә алыштыру мөмкинлегенә ия иде.

Шунысы куанычлы: Ураза бәйрәме, Корбан гаете уңаеннан уздырыла торган мондый бәйрәмнәр Чаллыда инде матур традициягә әверелеп бара. Элегрәк "Тәүбә", "Әбүзәр" мәчетләре дә балаларны шундый чаралар белән куандырган иде. Дәвамлы булсын дип кенә телисе кала!








Нәшире
Иршат Гыйльметдин улы
ШӘЙХАТТАР

Баш мөхәррир
Айгөл Абдуллина

Тел.: (8552) 70-51-09
Факс: (8552) 70-51-45

* * *

**Оештыручылары:**
Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте, "Ислам нуры" дини эшмәкәрлек Үзәге

Газета мәкаләләрен күчереп басканда аларның "Ислам нуры"ннан алынганын күрсәтү мәҗбүри.

Редакциягә килгән язмалар игътибар белән өйрәнелә, рецензияләнә. Хатлар газетага әзерләнгәндә авторларның стиле саклана.

**Хатларны 423802, Чаллы Үзәк ур., 72 адресы буенча юллау кирәк.**

**Электрон хатлар өчен: e-mail: islamnury@mail.ru**

Мөселманнар арасын бозуга, үзара каршылыкларга китерергә мөмкин булган хатлар, шикаятьләр газетада басылмый.

Дин-шәригать мәсьәләләренә кагылышлы язмалар, укучы сораулары Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые, Чаллы төбәге мөхтәсибәтенең гыйльми Советы тарафыннан өйрәнелә һәм аларга җавап бирелә.

Россия Федерациясе матбугат, телерадиотапшырулар һәм массакүләм коммуникацияләр Министрлыгының Идел буе төбәкара территориаль идарәсендә ПИ № 7-0997 саны белән 2001 елның 15 ноябрендә теркәлде.

"Роспечать" агентлыгы каталогына кертелгән, язылу ел әйләнәсендә Россия Федерациясе буенча алып барыла.

Айга ике мәртәбә чыга.

**Тиражы 1100.**

**Индексы 54149**

* * *

Хөрмәтле укучыбыз!

Газетабызны укып чыккач, аны туганнарыгызга, танышларыгызга, яки башка мөселманнарга тапшырсагыз иде. "Ислам нуры"ның һәр саны кулдан-кулга күчеп динебезне таратырга ярдәм итсә иде. Әмин.

Шулай ук укучыларыбыз, Коръән аятьләре язылу сәбәпле, газетаны кирәкмәгән урыннарга ташлаудан сакланырлар дип ышанабыз.

* * *

Газета компьютерда җыелды, офсет ысулы белән "Ислам нуры" басмаханәсендә басылды.

Нәшир һәм редакция адресы:
**423802, Яр Чаллы, Үзәк урамы, 72**

**Басарга кул куелды: график буенча 8 сентябрь 16 сәг. фактта 8 сентябрь 16 сәг.**

**Бәясе ирекле**

Ислам Нуры